Республика Татарстан
СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

18 январь 2023 ел

№1

Саба шәһәр җирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән 11.03.2016 ел, №16 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфа биләүчеләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырылуы турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Район прокуратурасының 11.01.2023 ел, №02-08-02/8-23-20920031 протесты нигезендә Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

**1.** Саба шәһәр җирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән 11.03.2016 ел, №16 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфа биләүчеләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырылуы турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфа биләүчеләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырылуы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфа биләүчеләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырылуы турында Нигезләмәнең 8нче пунктындагы 3нче п.п. түбәндәгечә бәян итәргә:

3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (катнашу өлешләре, оешмаларның устав (туплау) капиталында пайлар), цифрлы финанс

активлары, хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр хисап чорына кадәрге өч ел эчендә әлеге гражданның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кереме һәм акча алу чыганаклары турында, алар хисабына эшләнелгән әлеге алыш-бирешләрдән артып китсә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/saba адрес буенча бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен контрольгә алуны үз өстемдә калдырам.

Җирлек башлыгы Р.М. Хәсәнов